ҖОМГА
23 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 44 (5844)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Данлыклы XXII ел

Бүген Ватаныбызның хезмәт ияләре Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең һәм Хәрби диңгез Флотының XXII еллыгын бәйрәм итәләр. Социалистик илнең армиясе XXII ел яшәү дәверендә үзенең героик хәрәкәтләре белән дан казанды, совет халкының, прогрессив кешелек дөньясының чиксез мәхәббәтен яулап алды.

Безнең Кызыл Армиябез гражданнар сугышы елларында, патша генералларына каршы, 14 империалистик илнең интервентларына каршы каты көрәш елларында туды һәм үсте. Бөтен дөнья хезмәт ияләренең бөек юлбашчылары Ленин һәм Сталин яңа типтагы армияне төзеп, аны Советлар республикасының дошманнарына каршы көрәшкә юнәлдерделәр һәм рухландырдылар. Ленин һәм Сталин җитәкчелегендәге армиянең сугышчылары үз бурычларын, ни өчен көрәшкәнлекләрен яхшы аңладылар һәм шуның өчен дә безнең армиябез җиңеп чыгучы булды: эчке һәм тышкы дошманнарны тар-мар итеп ташлады, юкка чыгарды.

Эшче-Крестьян Кызыл Армиясен һәм Хәрби Диңгез Флотын төзүдә, аның җиңүләрен оештыруда иптәш Сталинның роле әйтеп бетергесез зур. Ул, стратегик яктан гаять әһәмиятле планнарның авторы, турыдан-туры хәрби операцияләргә җитәкчелек итүче булды. Партия иптәш Сталинны гражданнар сугышының иң җаваплы участкыларына җибәрде һәм ул кыска гына срокта зур җиңүләрне тәэмин итте. Иптәш Сталин хәрби комиссарларның җитәкчесе һәм аларны тәрбияләүче булды. Партия җитәкчелегендә, иптәш Сталин җитәкчелегендә Кызыл Армиянең сугышчан командирлары һәм комиссарлары үсеп чыктылар.

Совет халкының һәм аның героик армиясенең көрәше бушка китмәде. Хәзер без бәхетле һәм шатлыклы илдә яшибез һәм Ленин—Сталин партиясенең җиңүчән байрагы астында тагын да яңа уңышлар яулап алу өчен көрәшәбез. Безнең илебез Сталинчыл бишьеллыклар елларында гаять куәтле социалистик держава булып әверелде.

Бөек Октябрь Социалистик революциясе армия белән халык арасында яңа мөнәсәбәт, дуслык һәм туганлык мөнәсәбәте тудырды. Кызыл Армия—чын мәгънәсе белән халык армиясе, хезмәт ияләренең иң сөекле армиясе. Дөньяда иң көчле һәм иң куәтле армия. Чөнки ул, „азат ителгән эшчеләр һәм крестьяннәр армиясе, ул Октябрь революциясе армиясе, пролетариат диктатурасы армиясе... Бездә... халык белән армия бер бөтен, бер семья булып торалар. Халык тарафыннан армиягә бездәге шикелле мәхәббәт һәм игтибар белән карау дөньяда бер җирдә дә юк. Бездә армияне яраталар, аны зурлыйлар, аның турында кайгырталар" (Сталин).

Безнең Кызыл Армиябез — ул, күп милләтле Советлар Союзы халыкларының туганлык, дуслык армиясе, халыкларның азатлыгын һәм бәйсезлеген саклаучы армия. Безнең Кызыл Армиябез— ул интернационализм рухында тәрбияләнгән һәм тәрбияләнә торган армия. Капиталистик илләрнең армияләренә капма-каршы буларак, безнең Кызыл Армиябез илләр арасында тынычлык саклау һәм аны һәр төрле юллар белән ныгыту рухында, башка илләрнең хезмәт ияләренә карата зур мәхәббәт һәм ихтирам күрсәтү рухында тәрбияләнә. Социалистик ил армиясенең көч һәм куәт чишмәсен тәшкил иткән үзенчәлекләр әнә шулар.

Безнең илебез—патриотлар иле, безнең армиябез—геройлар армиясе. Командованиенең сугышчан заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәгән һәм бу эштә батырлык күрсәткән өчен хөкүмәтебезнең югары бүләкләренә ия булган геройлар сафы көннән-көн киңәя бара. Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтларында үзләрен танытткан яңа геройлар үсеп чыктылар.

Хасан күле янында, Монголия Халык Республикасы чикләрендә Ватаныбыз патриотларының күрсәткән геройлыклары белән совет халкы мактана һәм горурлана. Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия хезмәт ияләрен Польша паннары изүеннән азат итү өчен Кызыл Армиябезнең героик көрәш көннәре совет халкында, бөтен дөнья хезмәт ияләрендә гаять зур шатлык һәм горурлык тудырды. Ак финнәргә каршы көрәштә, фин халкының азатлыгы һәм бәхте өчен, гүзәл илебезнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен көрәштә данлыклы Кызыл Армиянең күрсәткән батырлыклары бөек совет халкының героик тарихына матур сәхифә булып керер.

Совет халкы Ленин—Сталин партиясе байрагы астында тарихи җиңүләргә ирešте, Советлар иле дошманнарына җимергеч удар бирде. Ленин—Сталин партиясе тарафыннан җитәкчелек ителә торган совет халкы һәм Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе көтелмәгән һәр төрле очраклылыкларга хәзер торганнары хәлдә, үзенең дошманнарын киләчәктә дә тар-мар итәр. Героик халыкның героик армиясе бер вакытта да җиңелмәс! Безнең армиябез ул—җиңүче армия! Яшәсен Социализм иленең данлыклы армиясе!

АКТАНЫШ МТС ы ЭШЧЕЛӘРЕ ҺӘМ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ КОЛЛЕКТИВЫНА

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты Актаныш МТС ы коллективын илебезнең бөек бүләге—Ленин ордены алу белән чын күңелдән котлый.

Актаныш МТС ының эшчеләре—тракторчылары, комбайнчылары, барлык работниклары авыл хуҗалыгыбызны большевиклар партиясе һәм Совет хөкүмәте коралландырган гаять бай техникадан оста файдалану үрнәкләре күрсәтәләр, эшкә социалистик караш үрнәкләре күрсәтәләр. Үзләренең тырыш хезмәтләре белән алар колхоз строеның өзлексез үсүе һәм ныгуы өчен, илебездә авыл хуҗалыгы продуктларының муллыгы өчен, хезмәт ияләренең тагын да бәхетлерәк һәм шатлыклырак тормышлары өчен нык көрәшәләр.

ВКП(б) Өлкә Комитеты Совет хөкүмәтенең бөек бүләген Актаныш МТС ы коллективының намус белән аклаячагына, ел саен 8 миллиард пот ашлык җитештерү турында ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын һәм халыклар юлбашчысы иптәш Сталин күрсәтмәләрен тиз арада үтәү өчен армый-талмый көрәшәчәгенә ышаныч белдерә.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты.

***

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы авыл хуҗалыгын күтәрүдәге күренекле уңышлары өчен, 1937—1938 нче елларда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе күрсәткечләрен аттырып үтәгән өчен бөек бүләк—**Ленин ордены** алу белән Актаныш МТС ы эшчеләре һәм хезмәткәрләре коллективын тирән канәгатьләнү белән котлый. Бу уңышлар—машина-тракторлар паркына хезмәт күрсәтүче даими квалификацияле кадрларны ныгыту өчен, ел саен 8 миллиард пот ашлык җыеп алу турында иптәш Сталин күрсәтмәсен үтәү өчен МТС коллективының большевикларча көрәшенең нәтиҗәсе.

Татарстан АССР хөкүмәте ышана: бөек бүләк—**Ленин ордены** алу машина-трактор паркыннан иң яхшы файдалану өчен һәм киләчәктә ныклы иген уңышы алу өчен производствода яңа күтәренкелек белән һәм коллективның актив көрәше белән ныгытылыр.

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

21 нче февральдә фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

19 нчы февральдән 21 нче февральгә кадәр безнең гаскәрләр фронтта, шул исәптән Койвисто крепосте районында, дошманның 176 ныгытылган оборона пунктын алдылар, шуларның 37 се тимер-бетоннан ясалган артиллерия корылмалары.

Безнең авиация дошман гаскәрләренә һәм аның сугыш объектларына актив сугыш хәрәкәтләре алып барды. Һавада булган сугышларда дошманның 16 самолеты бәреп төшерелде.

Художник Г. Поляков рәсме.

ПАТРИОТЛАР ҖЫРЫ

Без совет баһадирлары
Кыю һәм нык атлыйбыз,
Илебезне—даныбызны,
Кызганмыйча каныбызны
Җаныбыз күк саклыйбыз!

Кайнар сугышлы
Еллар кичтек без,
Шул еллар аша
Гөрләп үстек без,
Шул еллар безгә
Дан китерделәр,
Азатлык, хаклык,
Шатлык бирделәр.

Без совет баһадирлары
Кыю һәм нык атлыйбыз,
Илебезне—даныбызны,
Кызганмыйча каныбызны
Җаныбыз күк саклыйбыз!

Коллык газабын
Җимереп чыныктык,
Илебез өчен
Походка чыктык,
Баһадирларны
Менә карагыз:
Җирне селкетеп
Җырлап барабыз.

Без совет баһадирлары
Кыю һәм нык атлыйбыз,
Илебезне—даныбызны,
Кызганмыйча каныбызны
Җаныбыз күк саклыйбыз!

Совет җиренә
Кул сузучының,
Сугыш утлары
Кабызучының
Үзен яндырып
Әнә шул утта,
Көл итәр өчен
Чыктык походка!

Без совет баһадирлары
Кыю һәм нык атлыйбыз,
Илебезне—даныбызны,
Кызганмыйча каныбызны
Җаныбыз күк саклыйбыз!

Без үстек илнең
Тәрбиясендә,
Һәм аның шанлы
Армиясендә
Хезмәт итәбез—
Һәм хәтта җил дә
Тидертмәбез без
Кадерле илгә!

Без совет баһадирлары
Кыю һәм нык атлыйбыз,
Илебезне—даныбызны,
Кызганмыйча каныбызны
Җаныбыз күк саклыйбыз!

М. Садрый.
1940.

Эшче һәм крестьяннәрнең җиңелмәслек армиясе

А. Д. ЛОКТИОНОВ

II нче ранг командарм, СССР оборона халык комиссары урынбасары

1918 нче елны, Бөтенроссия Советларының III нче съездында Владимир Ильич Ленин үзе күргән бер вакыйга турында сөйләде:

„Бу эш Финляндия тимер юлы вагонында булды. Анда мина берничә фин белән бер карчык арасындагы сөйләшүне ишетергә туры килде. Мин фин телен белмәгәнлегемнән сөйләшүдә катнаша алмадым, ләкин бер фин миңа карап әйтте: „Беләсезме, бу карчык бик кызыклы бер нәрсә әйтте. Ул болай диде: хәзер инде мылтыклы кешедән куркырга кирәкми. Мин урманда барганда мина мылтыклы кеше очрады һәм минем җыйган чыбыкларымны тартып аласы урында, ул мина тагын өстәде" (Ленин, XXII нче том, 211 нче бит)

Владимир Ильич сөйләгән вакыйга булганнан бирле 20 елдан артык вакыт үтте. Хәзер, безнең көннәрдә, Маннергейм—Таннер ак бандитларына каршы көрәшүче фин халкына батыр Кызыл Армия туганлык ярдәме кулын сузганда, бу вакыйганең тирән символик әһәмияте аеруча ачык күренә.

Бөек Октябрь Социалистик Революциясенә кадәр мылтыклы кешедән курыккан, аны башбаштаклык, изү һәм көчләү символы дип караган гади бер хатын патша армиясе белән пролетариат диктатурасы армиясе, азат ителгән эшчеләр һәм крестьяннәр армиясе арасындагы аерманың нинди зур икәнлеген шунда ук сизгән. Хәзердә дә империалистик коллыктан Кызыл Армия тарафыннан азат ителүче фин эшчеләре һәм крестьяннәре безнең сугышчыларыбызны котлыйлар, чөнки алар Кызыл Армиянең—хезмәт ияләренең дусы һәм яклаучысы икәнлеген беләләр.

Нак менә шуңа күрә дә, ягни безнең Кызыл Армиябез Октябрь революциясенең баласы, „эшчеләрне һәм крестьяннәрне алпавытлар һәм капиталистлар изүеннән коткару коралы" (Сталин) булганга күрә дә ул яши башлавының беренче көннәреннән үк эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең игтибары һәм мәхәббәте белән чолгап алынды.

Гражданнар сугышы елларында, илебез җимереклектән, ачлыктан, империалистик сугыш нәтиҗәләреннән, ак гвардеецларның һәм интервентларның ерткычлыкларыннан хәлсезләнгән вакытта, һәрбер аңлы хезмәт иясе Кызыл Армиягә кулыннан килгән ярдәмне күрсәтергә тырышты.

Хәзерге вакытта фин халкын ак бандитлар өереннән азат итүче безнең хәрби частьләребез җиңеп алга баралар, чөнки аларга 183 миллион халык булышлык һәм теләктәшлек күрсәтә, аларга фин халкы булыша һәм теләктәшлек итә. Ак фин бандалары тар-мар ителәчәкләр һәм юк ителәчәкләр, чөнки фин халкы аларны дошман күрә, фин халкы карашында Маннергейм һәм аның компаниясенең хөкем сөрүе дар агачларына, атып үтерүләргә, хәерчелеккә һәм ачлыкка бәйләнгән.

Илебезнең коралды көчләрен тагын да яхшырту өстендә Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә армый-талмый эшләүче безнең халкыбыз Кызыл Армия интереслары белән яши.

Каны һәм тәне белән үз халкыныкы булган Кызыл Армия социалистик Ватан интереслары белән яши. Бу интересларны саклауга безнең сугышчыларыбыз, командирларыбыз, политработникларыбыз үзләренең бөтен көчләрен, бөтен уйларын һәм, әгәр кирәк булса, тормышларын да бирәләр.

Курыкмыйча сугышка баручы һәм дошманны җиңүче геройларыбызның күренекле батырлыклары турындагы хәбәрләрне без сокланып каршылыйбыз. Хөкүмәт геройны бүләкли һәм аның шатлыгы һәрбер совет гражданинының шатлыгы булып әверелә.

Истребительләр подразделениесе командиры, майор В. Ф. Скобарихин 22 тапкыр һава сугышында катнашты. Дошманның 5 самолетын ул бер үзе бәреп төшерде. Шуның өстенә ул үзенең иптәшләре белән бергәләп тагын 6 машинаны бәреп төшерде. Шушы сугышчан хезмәтләре өчен иптәш Скобарихинга Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Халык бу Сталинчыл лачынны, үзенең лаеклы һәм чын күңелдән бирелгән улын котлый.

Батальон командиры, майор Н. М. Бубнов, күп кенә сугышларда катнашып, яраланды, ләкин үзенең постында калды һәм үзенең сугышчылары белән бергәләп, дошманның күп кенә җанлы көчләрен сафтан чыгарды. Сугышларның берсендә бу батальонның иптәш Бубнов җитәкчелегендәге бер ротасы дошманның 200 снайпердан һәм 50 офицердан тора торган снайперлар мәктәбен юк итте. Хөкүмәт данлыклы командирны Ленин ордены белән бүләкләде.

Хасан геройлары, Халхин-Гол геройлары, Көнбатыш Украинадагы һәм Көнбатыш Белоруссиядәге туганнарыбызны азат итүче геройлар Ватан турында, партия турында, Сталин турында уйлап батырлык могҗизалары күрсәттеләр. Хәзер фин ак гвардеецларын тар-мар итүче герой сугышчыларыбыз һәм кызыл флотчыларыбыз батырлык могҗизалары күрсәтәләр. Алар дошманның мәкерле методларына да карамастан, тормышларын куркыныч астына куеп, сугыш заданиеләрен үтиләр. Иң кискен минутларда рядовой сугышчылар кыю карарларга киләләр һәм без аларның үз-үзләрен тота белүләре белән, кискенлекләре белән, иң авыр хәлләрдән дә котыла белүләре белән горурланабыз.

Менә бик күп сугыш эпизодларыннан берсе.

Ак финнәрнең бер отряды полк штабының команда пунктын саклаучы ротага һөҗүм иткән. Шул вакыт якыннан гына кызыл армеец Анатолий Койда үзенең тракторында сугышчыларга сугыш кирәк-яраклары һәм азык алып бара икән. Иптәш Койда тракторыннан сикереп төшә дә пулеметка тотына һәм дошманга каршы ут ача. Ак финнәр бер-бер артлы егылып, үзләренең үлек гәүдәләре белән кар өстен каплыйлар. Койданың актык патроны беткәндә инде атака тукталган була.

Ләкин озак та үтми шюцкорчылар янадан һөҗүм итә башлыйлар. Шул чагында Койда үзенең тракторына сикереп менә һәм зур тизлек белән дошманның нак уртасына кисеп керә. Ул аларны трактор белән таптата. Аның батырлыгы белән гайрәтләнеп кызыл армеецлар штыклар белән һөҗүмгә күчәләр. Ак финнәр зур югалтуларга дучар булып чигенәләр.

Бөек Ленин—Сталин партиясе безнең халкыбызда коммунистик җәмгыять кешесе сыйфатларын тәрбияли. Миллионнарча совет кешеләренә хас булган бу сыйфатлар Кызыл Армиянең Ватан өчен булган сугышларында ачык күренәләр. Аерым алганда бу сыйфатлар безнең сугышчыларыбызны хәтта тормыш өчен куркынычлы булган хәлләрдә дә бер-берләренә ярдәмгә барырга күнектерүче, гадәттән тыш дуслык, иптәшлек бәйләнешендә дә күренә. Дошман белән булган бер һава сугышында безнең бер очучыбызның самолеты зарарлана һәм очучы үлем куркынычы алдында кала. Югарыда әйтелгән майор Скобарихин үзенең иптәшенә ярдәм итү өчен үз самолетының канатлары һәм пропеллеры белән дошманның самолетына китереп бәрә. Дошман истребителе кисәкләргә таркала. Скобарихинның да машинасы зарарлана, ләкин ул аны уңайлы гына итеп җиргә төшерә.

Кызыл армеец И. К. Титов, разведкада чагында үзенең яраланган иптәшен ут астыннан коткарып алып чыга һәм соңыннан кире барып аның коралын алып кайта. Советлар Союзы Герое, батальонный комиссар Д. А. Балаханов сугыш вактында үзенең яраланган 15 иптәшен коткарып кала. Советлар Союзы Герое, кызыл армеец Н. И. Русин үзенең авыр яраланган иптәшен коткара. Очучы-истребитель, өлкән лейтенант М. П. Подобед дошман самолетын бәреп төшергәч тә үзенең яраланган иптәшен эзләргә китә һәм аны табуда ярдәм итә. Сугышчы Грушин разведкада чагында агач башына менгән бер ак финнең якында гына торучы батальонный комиссарга атарга хәзерләнүен күреп ала. Винтовкадан бик оста атып Грушин бу ак финне бәреп төшерә һәм шулай итеп үзенең иптәшен коткара.

10 нчы февральдә ак финнәрнең атакасы вактында өлкән лейтенант Мазаев алып бара торган бомбардировщикка зенит артиллериясе снаряды тия һәм яна башлый. Иптәш Мазаев каушап калмый, машинаны күл өстенә төшерә, ләкин ул безнең алгы позицияләребез белән ак финнәр позицияләре арасына килеп төшкән булып чыга. Яна торган самолетка дошман мылтыктан һәм пулеметтан ут ача. Иптәшләрнең куркыныч алдында калуларын күреп, эскадрилья командиры ярдәмчесе иптәш Трусов шунда ук иптәш Мазаев самолеты янына төшә һәм аның 3 кешелек бөтен экипажын үз машинасына ала. Ак финнәрнең уты астында иптәш Трусов самолеты һавага күтәрелә һәм үзенең базасына кайта. Бу вакытта истребительләр эскадрильясе командиры капитан Локатанов пулеметтан ут ачып һәм бомбалар ташлап дошманның ут точкаларын бастыра һәм шулай итеп үзенең иптәшләренә ярдәм күрсәтә.

Үзләренең армияләре политик хокуклардан мәхрүм ителгән буржуаз дәүләтләрдән аермалы буларак, Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының сугышчылары, командирлары һәм политработниклары үз илләренең тулы хокуклы гражданнары, алар аның политик, хуҗалык һәм культура тормышында актив катнашалар.

1928 нче елны Москва Советының тантаналы пленумында иптәш Сталин Кызыл Армиянең „эшчеләр һәм крестьяннәр белән туганнарча элемтәсе безнең Кызыл Армиябездә саклансын һәм ныгытылсын" дигән теләк белдерде.

Сөекле юлбашчыбызның һәм остазыбызның бу акыллы күрсәтмәсен халкыбыз чын күңелдән үти. Халык үзенең сөекле баласын—Кызыл Армияне күз алмасы кебек саклый.

Чын халык армиясе җиңелмәслек!

ЯШӘСЕН ТУГАНЫБЫЗ КЫЗЫЛ АРМИЯ — БӨЕК ОКТЯБРЬ СОЦИАЛИСТИК РЕВОЛЮЦИЯСЕНЕҢ КАЗАНЫШЛАРЫН ТУРЫЛЫКЛЫ САКЛАУЧЫ!

Куйбышев шәһәренә якын, табигый матур җирдә Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең санаториясе урнашкан. РӘСЕМДӘ: санаториядә ял итүчеләр. Н. Славин фотосы (ТАСС фото-клишесе).

БӨЕК АЗАТЛЫК ПОХОДЫНЫҢ СУГЫШЧАН ОПЕРАЦИЯЛӘРЕ ТУРЫНДА

1939 нчы елның 17 нче сентябренә каршы төн киеренке шартларда үтте. Киев һәм Белоруссия махсус хәрби округларының сугышчан хәзерлек хәлендәге частьләре кардәшләребезне,—Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыкларын,—Польша паннары изүеннән азат итү өчен сугышка ташланырга сигнал бирелүен генә көттеләр.

Башында пан Мосьцицкий торган Польша хөкүмәте үзенең хәсрәт гарантлары булган Англиянен һәм Франциянен ярдәменнән мәхрум ителгәне хәлдә, Германия Армиясенең кысрыклавына түзә алмыйча үз дәүләтенең язмышы өчен җаваплылыкны өскә алудан куркып, халыкны язмыш кочагына ташлап хурлыклы рәвештә качты. Шушы моментта Советлар иленең хезмәт ияләре, Польша һәм бөтен дөнья хезмәт ияләре барлык изелгәннәрнең фикерләрен һәм өметләрен чагылдырган ялкынлы сүзләрне ишеттеләр. Кызыл Армиянең сугышчыларында һәм командирларында бу сүзләр һич кем каршы тора алмаслык какшамас көч булып әверелгән гаять зур күтәренкелек тудырды. Бу—Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыкларының тормышын һәм мөлкәтен Кызыл Армиянең сакчылыгы астына алу турында Совет хөкүмәтенең карары уңае белән хөкүмәт башлыгы иптәш В. М. Молотовның радио аша мөрәҗәгате иде.

Чикне үтеп керү турында Кызыл Армиянең баш командованиесенең сугышчан приказын без дөнья тарихында яңа полоса башлануны хәбәр иткән сигнал сыйфатында каршы алдык. Данлыклы Кызыл Армия Маркс—Энгельс—Ленин—Сталинның җиңелмәс бөек байрагы астында безнең туганнарыбызга бөек азатлык алып барды.

...Төн караңгылыгы эчендә, чик буе баганаларыннан 3—4 километр ераклыкта безнең штаб өзлексез эшли иде. Чик буендагы авылның башка өйләреннән бер нәрсә белән дә аерылмаган өйдә командирлар карталар буенча обстановканы билгелиләр, аларның читләренә үзләренең искәрмәләрен язып куялар иде. Иртә таң белән роталарны, батальоннарны, полкларны чик буе баганаларының аръягына алып керергә хәзерлек барды. Төн караңгылыгында командирлар белән сугышчылар арасында шул турыда сөйләшүләр алынып барылды.

Ракеталар сериясе чикне үтеп керүнең башлануы турында хәбәр итте. Без сугышчан хәзерлек хәлендә тора идек... Сәгатьнең стрелкалары 5 кә якынлашты. Уң флангда аткан тавыш ишетелде һәм аксыл ракета күктә төннең караңгылыгын ярып җибәрде. Тагын ату, бер-бер артлы ату китте һәм күп сандагы ракеталар дошманның чик буе зонасының алгы кырыен балкытты.

Дошман ягыннан берничә тапкыр ату булды, безнең пулемет шунда ук аңа җавап бирде. Тавышсыз-тынсыз гына диярлек, аерым-аерым булып, без алга атладык.

Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия хезмәт ияләрен азат итү буенча безнең операцияләр халыкның теләктәшлеге һәм булышлыгы белән шактый җиңеләйделәр.

Чик буе якынындагы кечкенә елганы беренче тапкыр аркылы чыкканда крестьяннәр, кайдан аркылы чыгарга мөмкин булуын күрсәтеп кенә калмадылар, хәтта күпер салу эшләрен дә оештырдылар.

Шәһәрләрдәге һәм авыллардагы хезмәт ияләре безне тантаналы рәвештә каршыладылар. Күп шәһәрләрдә һәм авылларда безнең частьләрнең юллары чәчәкләр белән капланды. Халык яшел торган пунктларга кергәндә яшел ылыслар һәм чәчәкләр белән бизәлгән аркалар аркылы үтәргә туры килә иде. Кызыл полотноларда без—„Хуш килдегез!", „Яшәсен дустыбыз һәм безне азат итүче җиңелмәс Кызыл Армия!" дигән сүзләрне укый идек.

Поляк офицерларын, жандармнарын, петлюрачыларны, махночыларны һәм башка дошманнарны тотуда партизаннар безнең разведкага бәя биреп бетерә алмаслык хезмәт күрсәтеп, безнең сугышчыларга зур булышлык күрсәттеләр.

Поляк офицерлары: Кызыл Армия Польша паннарына каршы түгел, бәлки Германиягә каршы сугышырга Польша армиясенә булышу өчен килде, дип халыкның башын әйләндерергә тырыштылар. Бу барып чыкмагач, алар, СССР да танклар фанердан ясалганнар, анда металл кытлыгы яшин, дигән ялган хәбәрләр таратканнар. Полякларның шундый әкиятләргә алданган эскадроны кылычлар белән безнең танкларга ташланды. Танкларның фанердан ясалмаган булуына ахырда ышандылар.

Польша буйлап үткәндә безнең частьләр, үз юлларында очраган паннар Польшасы гаскәрләрен себереп ташлап, һәр җирдә дә азатлык байрагы күтәреп бардылар. Үз юлыбызда без Польша җиренең бер генә почмагында да хәерчелек һәм кыргыйлану булмаган урынны очрата алмадык. Кергән бер шәһәрдә безгә сораулар яудырдылар. Слесарьлар, кузнецлар, итек тегүчеләр, токарьлар, техниклар, инженерлар һәм башкалар—барсы да „СССР да эш табып булмасмы?" дигән сорауларны бирделәр.

Инженерлар һәм техниклар, әгәр дә СССР да үзләрен кара эшче сыйфатында эшкә алсалар да, бик шат булачакларын белдерделәр. Чөнки үз семьяларен ачлыктан, хәерчелектән коткару өчен, алар Польшада кара эш тә таба алмаганнар. Польша крестьяннәре бөтенләй хәлдән тайганнар, таланып беткәннәр.

Күп сугышчылар һәм командирлар чынчыннан геройлык күрсәттеләр. Безнең частьтән бер старшина, төнлә поляк батальоны урнашкан урынга барып кереп, курыкмады гына түгел, киресенчә, хәрби хәйләкәрлек методлары белән дошманны саташтырды һәм поляк батальоны командирын үз батальонына коралларны ташлау турында боерык бирергә, ә аннары бөтен батальонны коралсыз килеш безнең тылга озатырга мәҗбүр итте.

Бер батальонга якын поляк солдатлары Кызыл Армиянең 17 кешелек группасы тарафыннан командованиесе һәм кораллары белән пленгә алынды. Андый мисальләрне күп китерергә мөмкин, сугыш барган вакытта алар турында матбугатта язылды.

Сугыш нәтиҗәсендә, Польша дәүләте җир йөзеннән себереп ташланды. Көнбатыш Украинаның һәм Көнбатыш Белоруссиянең азат ителгән хезмәт ияләре бөек совет семьясенә кушылып, үзләренең бәхетле тормышын төзи башладылар.

Капитан — А. И. Комяков.

Социализм иленең куәтле флоты

Г. ЛЕВЧЕНКО

1 нче ранг флагман, ССР Союзы Хәрби Диңгез Флоты халык комиссарының урынбасары

Пролетар революциянең бөек мастерлары һәм даһилары Ленин һәм Сталин җитәкчелегендә большевистик партия һәм Совет хөкүмәте Бөек Октябрь Социалистик революциясенең җиңүе белән үк Кызыл Хәрби Диңгез Флотының нигезен салдылар. Октябрь революциясенә кадәр үк инде Ленин һәм Сталинның турыдан-туры күрсәтмәләре буенча большевиклар 15 еллар буена флотта актив оештыру-партия эше, пропаганда һәм агитация эше алып бардылар. 1905 нче һәм 1917 нче еллардагы буржуаз-демократик революцияләрдә һәм бигрәк тә Октябрь Социалистик революциясендә моряклрның героик.революцион чыгышларында бу эшләрнең нәтиҗәләре бик ачык күренде.

Ленин һәм Сталинның күрсәтмәләре һәм боерыклары буенча кызыл моряклар гражданнар сугышы фронтларына бардылар. Коры җирдәге фронтларда: пехотада һәм кавалериядә, артиллерия һәм пулемет частьләрендә, бронепоездларда 60 меңгә якын моряк сугышты.

Краснов, Каледин, Колчак, Деникин, Юденич, Врангель бандаларына каршы, ак поляк гаскәрләренә каршы, фин ак контрреволюциясенә һәм күп кенә башка интервентларга каршы көрәш елга, диңгез һәм күл чикләрендә аеруча нык һәм каты булды. Пролетариатның даһи юлбашчылары, социалистик революциянең сыналган стратеглары һәм полководецлары Ленин һәм Сталин Волгада, Камада, Днепрда, Төньяк Двинада, Каспий диңгезендә, Ладога һәм Онега күлләрендә хәрби флотилиеләр төзүгә үзләре җитәкчелек иттеләр. Алар пролетар революциянең йөрәге булган Петроградка килә торган юлларны саклаучы Балтыйк флотының сугышчан сәләте турында кайгыртучанлык күрсәттеләр.

Безнең кызыл моряклрыбыз дошманның флотларына һәм флотилиеләренә каршы йөзләрчә данлыклы героик операцияләр үткәрделәр. 1918—1919 нчы елларда Балтыйк диңгезендә генә дә кызыл флотчылар Англиянең 16 сугыш карабын батырдылар. Волгада һәм Камада Колчак флотилиесенең барлык караблары юк ителде яки пленгә алынды.

Гражданнар сугышы дошманны тулысынча тар-мар итү белән тәмам булды.

Кызыл диңгез флотының хәле чиктән тыш авыр иде. Личный состав бик аз иде, шуның өстенә ул череп таралган һәм контрреволюцион элементлар белән чүпләнгән иде. Карабларга нормаль ремонт булмады, күмер һәм нефть җитешмәде.

Хәрби Диңгез Флотын аякка бастыру һәм аның куәтен ныгыту турындагы мәсьәлә бөтен халык өчен зур әһәмиятле бурыч сыйфатында партия һәм хөкүмәт алдына килеп басты. Ленин—Сталин комсомолы 1921 нче елны ук инде иң яхшы комсомолецлардан 2.000 кешене флотка җибәрде, 300 кеше команда составы училищеләренә җибәрелде.

1922 нче елның октябрендә комсомол флотны шефка алды һәм флот комсомолдан регуляр рәвештә өстәмә көчләр ала башлады. Карабларда көчле эш башланды—флот аякка баса башлады.

1922 нче елның көзендә „Марат" линейный карабына ремонт ясалды һәм ул Балтыйк диңгезендә хәрәкәттәге хәрби караблар сафына керде. 1923 нче елның 1 нче маена Кара диңгездә „Коминтерн" крейсере һәм башка караблар йөртелә башлады.

Партия һәм иптәш Сталин үзе, аның иң якын көрәштәшләре М. В. Фрунзе, К. Е. Ворошилов, С. М. Киров флотның үсүен кайгыртучанлык һәм игтибар белән күзәттеләр. Ул вакыттан бирле безнең хәрби корабларыбыз күп тапкырлар данлыклы походлар үткәрделәр. Алар Европаның һәм Азиянең барлык диңгезләрендә, җир шарының барлык океаннарында булдылар. Европа, Азия, Америка һәм Африка халыклары куәтле социалистик державаның хәрби диңгез флагын күрделәр.

Социалистик дәүләтебезнең ныгуы империалистларда бик нык ачу тудырды. Империалистлар бу еллар эчендә Советка каршы зур сугышка хәзерләнделәр. Капиталистик дәүләтләр хәрби диңгез төзелешен киң җәелдерделәр.

Совет халкы Ватаныбыз өчен елдан-ел үсеп бара торган бу куркынычка өстән генә карап кала ала идеме соң? Юк, карап кала алмый иде. Без чикләребезнең оборона таләпләренә туры китереп һәм материаль-техник мөмкинлекләребездән чыгып Хәрби Диңгез Флоты төзедек. Илебезне индустрияләштерүнең уңышлары, Сталинчыл бишьеллыкларның җиңүләре яңа хәрби караблар төзүгә күчәргә мөмкинлек бирделәр.

Советлар Союзы—бөек диңгез державасы, аңа зур Хәрби Диңгез Флоты кирәк. Безгә барыннан да элек флотның җиңел көчләрен: су асты көймәләрен, торпеда катерларын һәм башкаларны төзергә кирәк иде. Безнең суднолар төзелеше һәм машиналар төзелеше промышленносте бу мактаулы бурычны бик яхшы үтәде.

Хәзер бездә куәтле дүрт хәрби диңгез флоты—Кызыл Байраклы Балтыйк, Кара диңгез, Төньяк, Тын океан флотлары һәм берничә елга һәм диңгез флотилиесе бар. Су асты көймәләренең һәм торпеда катерларының саны буенча безнең ил дөньяда беренче урында тора. Безнең сугыш карабларыбыз үзләренең сугышчан сыйфатлары ягыннан чит илләрнең иң яхшы карабларыннан күп яктан өстен торалар.

Совет хөкүмәте Кызыл Байраклы Балтыйк Флотының начальниклар составының һәм кызыл флотчыларының кыюлыгына һәм батырлыгына югары бәя бирде. Советлар Союзы Геройлары семьясенә куркусыз хәрби моряклар һәм диңгез очучылары өстәлде. Күп кенә командирлар һәм кызыл флотчылар орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде. „С—1" һәм „Щ—311" су асты көймәләре „Кызыл Байрак" ордены белән бүләкләнделәр.

1939 нчы елның 24 нче июлендә илебез беренче тапкыр буларак „Хәрби Диңгез Флоты Көне"н бәйрәм итте. Бу көндә Флотның Хәрби һәм политик хәзерлектәге иң яхшы казанышлары күрсәтелде, флотның халык белән аерылмаслык элемтәсе күрсәтелде.

Советлар Союзының изге диңгез чикләренә кул сузарга омтылучы нинди генә дошман булмасын, кызыл флот тарафыннан тар-мар ителәчәк һәм су төбенә җибәреләчәк.

Сталин һәм Ворошилов иптәшләр.

И. Игорьянов фотосы (Союзфото репродукциясе)

Сакта тора лачын егетләр

Зур гигантлар үсә илемдә,
Хезмәт—
бәхет бөтен җирендә.
Байлык артсын өчен
тагын да,
Һәм мул итәр өчен
барын да
Сакта тора
лачын егетләр,
Бар да алар
тимер кебекләр.
Тыныч илнең
матур таңында
Профессор китап
язганда,
Бүленмәсен өчен
юллары,
Чуалмасын өчен
уйлары,
Сакта тора
лачын егетләр,
Бар да алар
тимер кебекләр.

Кошлар сайрый
киң урманнарда,
Бодай үсә иркен кырларда,
Тапталмасын өчен
ашлыклар,
Тыныч булсын өчен
халыклар,
Сакта тора
лачын егетләр,
Бар да алар
тимер кебекләр.
Яшь бер бала йоклый
бишектә,
Уяна ул тавыш ишетсә.
Тынычлыкка хаклы
тормышы
Татлы булсын өчен йокысы,
Сакта тора
лачын егетләр,
Бар да алар
тимер кебекләр.

Г. Латыйп.

Кыйммәтле адрес

Күңлем таша әгәр хат язмасам
Җылы хисләр белән тутырып,
Ерак җирдә якын сердәш булсын
Укыганда кичләр утырып.

Шушы уйлар кайнар тойгы
белән
Борчыгачтан Гайшә апаны
Стенадан алып карточканы
Кочып үпте улын—Сафаны.

Карточкадан Сафа карый иде,
Тере кебек нурлы күз белән
„Син пошынма, әнкәй" дигән
кебек
Әйтәсыман җылы сүз белән.

— „Әйе,—диде кинәт Гайшә
апа—
Батырларча алга атладың
Гомереңне биреп халык өчен
Ватаныңны улым сакладың.

Ярый бәпкәм, язам бу хатыма,
Хисләремә манып каләмне,
Укысыннар сине искә алып, —
Әнкәң язган кайнар сәламне.

Сәлам сезгә, батыр сугышчанлар
Сезгә яза Сафа анасы,
Сез дә якын миңа улым кебек
Шуңар күрә килә язасым.

Минем хатым сезгә барып
җиткәч
Командирга илтеп бирегез
Гайшә апа безгә кушкан диеп,
Киң маңлаен сөеп үбегез.

Сезнең хатны алгач һәр кич
саен
Мин укырмын күзлегем киеп,
Шатлыгымны котлап мин
йөрермен
Иң яраткан күлмәгем киеп.

Мин онытмам сезнең адресны
Ул һәр вакыт торыр күңелдә
Кызыл йолдыз кебек җылы
булып
Сакланачак йөрәк түрендә.

Гомәр Кучербаев.



СОЦИАЛИЗМ ИЛЕ АРМИЯСЕНӘ БӨЕК ДАН!

СУГЫШ ЧУКМАРЛАРЫНА ОНТЫЛМАСЛЫК САБАК

Миңа Хасан күле районында булган сугышларда катнашу бәхете туры килде. Бәйләреннән ычкынган япон сугыш чукмарларына безнең Кызыл Армиябез бик яхшы һәм онтылмаслык сабак бирде.

Ул вакыттан бирле бер ел ярым вакыт үтте, ләкин Хасан көннәренең сугышчан эпизодлары минем хәтеремдә нык сакланалар.

Совет җиренә һөҗүм итүне японнар озак һәм җентекләп хәзерләделәр. Хасан күле районында японнарның баштан аяк коралланган берничә дивизияләре тупланган иде. Самурайлар бик тиз генә җиңәргә уйладылар, ләкин алар үзләренең исәпләрендә нык ялгыштылар.

— Кызыл сугышчылар „Ватан өчен! Сталин өчен!" дигән авазлар белән алга, дошманга каршы бардылар.

Безнең часть чик буенда ук тора иде. Япония империалистлары совет территориясенә кораллы һөҗүм ясау белән үк, совет командованиесе туган җиребезне һәм халкыбызны саклау өчен самурайларга каршы чыгарга приказ бирде. Без сугышка гаят зур күтәренкелек белән бардык. Кызыл сугышчылар бер теләк белән—самурайларны нык кыйнау теләге белән—сугарылганнар иде.

Мин ул чагында элемтә частендә отделение командиры булып хезмәт итә идем. Минем отделениегә батальоныбызны телефон элемтәсе белән өзлексез тәэмин итәргә приказ бирелде. Дошман уты астында телефон линиясе сузарга кирәк булды. Ләкин бу безне куркытмады. Сугышның уңышлары элемтәне тиз урнаштыруга бәйләнгәнлеген һәрбер сугышчы бик яхшы белә иде. Моны японнар да аңладылар. Алар безгә каршы көчле ут ачтылар. Безгә берничә тапкыр телефон катушкаларын калдырырга, гранаталар һәм штыклар белән эш итәргә туры килде.

Самурайларның беренче группасы безгә Хасан күле янында очрады. Алар унбишләп бар иде, ә без алты кеше идек. Көчләр тигез түгел. Ләкин җиңүгә һәм эшебезнең дөреслегенә ышану бу тигез булмаган бәрелештә безгә көч бирде. Без самурайларга каршы ут ачтык, алар чыдый алмадылар, берничә минуттан качарга мәҗбүр булдылар.

Икенче тапкыр японнар безнең отделениегә без телефон станциясен икенче урынга күчергән вакытта һөҗүм иттеләр. Ләкин дошман бу юлы да элемтәне җимерә алмады. Мин берничә сугышчыма дошманга каршы ут ачарга приказ биреп, башкалары белән эшне дәвам иттердем. Берникадәр вакыттан соң мин батальон командирына приказның үтәлгәнлеге турында хәбәр иттем.

Хасан күле районындагы вакыйгалар сугышчан эпизодларга бай. Сугышчыларыбызның һәм командирларыбызның батырлыклары, үзләрен аямыйча сугышулары, сугышчан осталыклары һәм тиңдәшсез кыюлыклары турында йөзләрчә мисальләр китерергә мөмкин. Менә ул эпизодларның берничәсе.

Заозерная биеклегендә безнең пулеметчикның сул кулы яраланды. Часть командиры аңа ут линиясеннән чыгарга һәм бәйләү пунктына барырга приказ бирде. Бу эш төнлә белән иде. Пулеметчик, биеклектән төшкәндә караңгылыкта бер япон солдаты фигурасын күрә. Япон солдаты саклык белән генә яшренеп безнең гаскәрләр урнашкан урыннарга таба килә икән. Япон солдаты кораллы, ә безнең пулеметчикның кулында бер нәрсә дә юк. Пулеметчик тирә-якка карап ала да, самурайлар ташлап киткән бер тимер көрәкне күрә. Пулеметчик көрәкне ала да дошман өстенә ыргыла һәм дошманны шунда ук юк итә. Шуннан соң бәйләү пунктына китә.

Танкка каршы орудиеләрдән атуга җитәкчелек итүче кече командир Пайвин, еракта, тимер юлда, япон позицияләренә таба килә торган хәрби поездны күрә. Пайвин поездны юк итәргә карар бирә. Ләкин поезд ерак була, Пайвин поездга ут ачу өчен батарея командирыннан рөхсәт сорый. Ул бик тизлек белән поезд алдында бер нокта билгели, эшелонның уртасы шушы нокта турысына килеп җиткәч тә, ут ача. Төз атылган снаряд максатка туры килә. Поезд тау астына төшеп китә. Пайвин тагын ике снаряд ата һәм унбиш вагоннан гыйбарәт булган поездан вагоннарның ватыклары гына калалар.

Япон армиясенең җиңелмәслеге һәм самурайларның сугышчан рухы турындагы легенда Хасан суында күбек булып күккә очты.

Хасан — хәзер японнар өчен куркынычлы сүз. Кызыл Армия социалистик Ватанның даны өчен, совет халкының даны өчен, бөек Сталин исме белән сугышка барды һәм җиңде, үзенең данлыклы тарихына тагын бер гүзәл сәхифәне язды.

А. А. Поворов.
Хасан күле янындагы сугышларда катнашучы.

Кызыл Армия—геройлар армиясе

Пролетар революциясе һәм гражданнар сугышы тарихы, шулай ук 1939—40 нчы елларда Кызыл Армиябезнең азат итү хәрәкәтләре фронтта да, шулай ук тылда да массовый гүзәл героизм үрнәкләре белән тулган.

Гражданнар сугышының легендар геройлары Чапаев, Щорс, Котовский, Пархоменко, Лазо, Дундич, Руднев барыбызга да билгеле, алар совет халкының йөрәгендә яшиләр. Аларның батырлыклары социализм чоры геройларының батырлыкларына бәйләнгән. Безнең илебездә геройлык совет халкының тормышына һәм көнкүрешенә керде. „Стахановча эшләргә, дошманны Хасандагыча кыйнарга" дигән лозунг совет патриотизмының байрагы булып әверелде.

Кызыл Армиябезнең шушы лозунг белән рухланган сугышчылары Хасан күле районында, Халхин-Голда, Көнбатыш Украинада һәм Көнбатыш Белоруссиядә булган сугышларның уңышларын тәэмин иттеләр. Хәзер бу лозунг төньяк-көнбатыш чикләребезгә куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен фин ак гвардеецларына каршы көрәштә яңа көч белән тормышка ашырыла.

Хасан күле районындагы сугышта геройлык, батырлык һәм йөрәклелек күрсәткән өчен данлыклы 26 патриотка Советлар Союзы Герое исме бирелде, 95 кеше Ленин ордены белән, 1.982 кеше „Кызыл Байрак" ордены белән, 1.935 кеше „Кызыл Йолдыз" ордены белән, 1.326 кеше „Батырлык өчен" медале белән һәм 1.159 кеше „Сугышчан хезмәтләр өчен" медале белән бүләкләнде.

1939 нчы елны совет геройларының данлыклы семьясендә Ватаныбызның өч кыю лачыннарына—Кравченко, Смушкевич, Грицев иптәшләргә икенче тапкыр Советлар Союзы Герое исме бирелде. Ә 1940 нчы елны легендар Папанинга икенче тапкыр Советлар Союзы Герое исме бирелде.

Фин ак гвардеецларына каршы көрәшнең өч ае эчендә Кызыл Армиябез тагын да гаять зур дан казанды. 15 нче январьда СССР Верховный Советы Президиумы кызыл армеецлардән һәм командирлардан 27 кешегә Советлар Союзы Герое исме бирде.

Комиссар Пожарский, икенче ранг командарм Штерн, комкор Жуков, өлкән лейтенант Кукин, кече командир Козлитин, кызыл армеецлар Чуйков, Соломонников иптәшләрнең һәм күп кенә башкаларның исемнәре безнең яш буынның хәтерендә мәңге сакланыр.

Халкыбызның иң яхшы вәкилләре тарафыннан күрсәтелгән бу геройлыклар Сталин эпохасы кешеләренең, иптәш Сталин тәрбияләп үстергән кешеләрнең нәрсәгә сәләтле икәнлекләрен бөтен дөньяга күрсәттеләр.

Узган елны хәрби ант кабул иткәч, ике тапкыр Советлар Союзы Герое иптәш Кравченко тарафыннан әйтелгән сүзләр искә төшәләр:

„Миңа 26 яш, мин Совет власте елларында үстем, минем тормыш юлым безнең буын кешеләре өчен характерлы. Пионерлар мине тормыш юлына чыгардылар, комсомол һәм партия мине сугышчы итеп тәрбияләде. Бүген мин үз Ватанымны киләчәктә дә нык сакларга ант иттем. Әгәр дә Ватаныбыз кушса, һавага беренче булып күтәрелермен һәм дошманны тәмам җиңүгә ирешермен".

Ватан аңа яңа задание бирде. Герой үзенең сүзләрен практикада раслады. Ул ике тапкыр Советлар Союзы Герое булып әверелде.

Менә шуңа күрә дә безнең Советлар Союзында массовый җыр сүзләре гүзәл яңгырыйлар:

„Безнең һәр кайсыбыз герой була ала,
Герой булырга илебез чакырса".

Кызыл Армиягә бүген XXII яш тулды. Ул чын геройлар армиясе булды, шулай булып тора һәм киләчәктә дә шулай булыр, чөнки аңа социалистик хезмәтнең беренче герое бөек Сталин җитәкчелек итә.

Машнев.
Полковой комиссар.

ХАЛХИН-ГОЛ БУЕНДАГЫ КАЙБЕР ЭПИЗОДЛАР

Кызыл Армия Хасан күле районында япон самурайларына бик ныклы сабак бирде. Алар бу удардан соң бераз аңнарына килү белән, Монголия Халык Республикасы чигендә көч сынамакчы булдылар. Япон сугыш чукмарларының күзләрен кан баскан иде, алар Монголия Халык Республикасы белән Советлар Союзы арасында дуслык һәм үзара ярдәмләшү турында договор булганлыкны исәпкә алмаганнар булса кирәк.

Узган ел август аенда японнар Халхин-Гол елгасы буенда зур көчләр—йөзләрчә аэропланнар, танклар һәм орудиеләр тупладылар. Бу районда беренче зур сугыш 17 нче августта башланып китте. Мин ул вакытта элемтә частендә хезмәт итә идем. Сугыш башлану белән, миңа безнең команда пункты белән монгол дивизиясе штабы арасында телефон элемтәсе урнаштыру турында задание бирелде. Минем белән бергә тагын 3 сугышчы бар иде. Суы көчле рәвештә ага торган елга аркылы чыгарга һәм японнарның алгы линияләреннән ерак түгел бер урында телефон линиясе үткәрергә кирәк булды. Японнар безнең группаны күреп алып, пулеметлардан атарга керештеләр. Безнең баш өстендә пуляләр сызгырып торган хәлдә, без алга баруыбызны дәвам иттердек.

Самурайлар безгә бик нык комачауладылар. Үзебездән 2 километр ераклыкта мин кинәт безнең броневикларны күрдем. Ут линиясеннән чыгып, мин аларга таба йөгердем һәм ярдәм сорадым. Броневикларның берсе дошман блиндажына таба юнәлде һәм пулеметтан ут ачты. Японнарның 2 се үтерелде, калганнары, старшиналары белән берлектә, пленгә алындылар.

Аннан соң без дошман самолетының һәм авыр батареясының утына очрадык. Снарядлар телефон чыбыгын берничә тапкыр өзделәр, ләкин без аны бик тиз төзәттек. Безнең команда пунктлары арасындагы элемтәне бозарга самурайларның берничә тапкыр маташып караулары аларга бернинди нәтиҗә бирмәде. Сугышлар вактында телефон линиясе өзлексез эшләп торды. Бары тик бер генә тапкыр линия өзелгән иде. Юеш үлән өстенә төшеп калган эзләр буйлап без бер блиндажга килеп җиттек. Анда Кызыл Армия лейтенанты формасына киенгән һәм йоклап ята торган берәүне күрдек. Ул ак гвардеец булып чыкты. Без аны тотып штабка китердек һәм бу эш өчен безгә рәхмәт белдерелде.

Халхин-Гол буендагы сугышларда миңа безнең очучыларның осталыгын күзәтергә туры килде. Япон авиациясе монгол-совет эскадрильяләре белән булган сугышлардан зур югалтулар биреп чыга иде. 20 нче августта мин һава сугышы күрдем. Бу сугыш вактында безнең очучылар, үзләренең бер машиналарын да югалтмыйча, японнарның 7 самолетын бәреп төшерделәр.

Совет очучылары үзләренең чын-чыннан Сталин лачыннары икәнлекләрен күрсәттеләр. Алар иң кыен хәлләрдә дә җиңүчеләр булып чыгалар иде.

Безнең бер самолет дошманның зенит батареяларыннан ачылган ут белән зарарланды. Очучы парашют белән сикерде. Җил аны японнар ягына алып китте. Самурайлар куандылар. Алар кызыл очучыны тереләй алу мөмкинлегеннән шатландылар. Ләкин аларның шатланулары бик иртә булып чыкты. Безнең башка бер истребительнең очучысы, үз иптәшенең куркынычлы хәлдә икәнлеген күреп, японнарның позицияләре өстеннән давылдай булып узып китте һәм парашют җепләрен самолетның канаты белән эләктереп, парашюттагы иптәшне үзе белән алып китте. Японнар көтелмәгән хәл аркасында, югалып калдылар. Батыр очучыга алар ут ачкан вакытта инде соң иде. Парашютчы уңышлы рәвештә үзебезнең частьләр урнашкан җиргә төште.

Японнар Монголия буйлап җиңүле марш булдырырга хыялланганнар иде. Моннан бер нәрсә дә чыкмады. Ләкин япон генераллары үзләренең югары командованиеләренә дә үзләренең җиңелүләрен әйтергә оялдылар. Япон-манҗур бандаларының калдыклары монгол-совет гаскәрләре тарафыннан чолганып алынгач, аларның командующие генерал К. үзенең верховный командованиесенә ялган донесение җибәрә. Ул: „Совет гаскәрләре чолганып алындылар. Аларны тәмам кыйнап бетерү өчен өстәмә көч җибәрегез" ди.

Өстәмә көч килмәде. Аның каравы Кызыл Армия япон бандаларын тәмам беткәнче кыйнады.

Монголиянең иркен далаларында батыр Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе совет коралының куәтен һәм көчен тагын бер тапкыр күрсәтте.

Маннергеймнарның һәм таннерларның канлы шайкасы моны нык исендә тотсын. Хасан күле районында һәм Монголия Халык Республикасы чигендә япон самурайлары нинди сабак алган булсалар, ак фин бандаларын да шундый ук хәл көтә.

И. Отставнов.

РӘСЕМДӘ: Советлар Союзы Геройлары. Беренче рәттә (сулдан уңга) лейтенант И. Д. Чернопятко, лейтенант Г. А. Батыршин, кызыл армеец И. М. Ульянов, кече командир И. В. Просолов, кызыл армеец Г. С. Пулькин; икенче рәттә—өлкән лейтенант Л. А. Орлов, полковник В. Н. Кошуба, комкор Г. К. Жуков, лейтенант В. П. Трубаченко һәм кызыл армеец В. К. Артюк иптәшләр.

Геройлар иле

Бу көннәрдә,—җир шары империалистик сугыш уты белән яңадан чолганып алынганда һәм бөтен дөнья күләмендә яңа сугыш уты кабызучылар үз халыкларын алдау өчен махсус ялган информация министрлекләре төзегәндә,—Кызыл Армия данлы сугышларда үзенең азатлык роленең дөреслеген ныгыта.

Изге максатлар Кызыл Армияне көннән-көн чиксез күп санлы геройлык актларына рухландыралар. Кызыл Армия Финляндиянең хезмәтчел халкына ике йөзле юлбасарлардан һәм эксплоататорлардан азатлыкка омтылуында ярдәм итә; ул аның аерым милләт булып яшәве өчен шартлар тудыра; ул Советлар Союзын да, аның дус күршеләрен дә бөтен дөнья империализмының ерткыч һөҗүменнән сакларга сәләтле булган оборона оештыра.

Газеталарыбызның битләрендә бөек социалистик Ватан өчен көрәштә батырлык һәм куркусызлык данына күмелгән кешеләрнең исемнәре торган саен ешрак күренә. Советлар Союзы геройларының исемнәре арта.

Үзен һәр яктан чолгап алган күп санлы ак финнәрдән үз батареясен саклап кала алган батарея командиры Маргулисны хәзер кем белми! Кызыл артиллеристларның тиңдәшсез ныклыклары һәм батырлыклары шюцкорчыларның күп санлы бандасын мораль яктан таркатты. Ахрында дошман, сугыш урнында күп үлекләр калдырып, аз сандагы геройларның штык белән удар ясауларыннан куркып качты.

Кече лейтенант Николай Кичигин танкысы белән разведкадан үз часте урнашкан урынга кайтып килгәндә минага эләгә, мина шартлый һәм танк яна. Яшеренеп яткан җирдән чыккан дошман ут ача. Кече лейтенантның бугазы һәм тезе яралана. Шулай да ул һәлакәткә очраган машинадан үзенең тагын да ныграк яраланган иптәшләрен алып чыга һәм аларга беренче ярдәм күрсәтә. Дошман машинаны әйләндереп ала һәм аның экипажына якын килә башлый. Шул вакыт Николай Кичигин, үз тормышын куркыныч астында калдырып, янып торган танкка янадан керә, аннан ящик белән гранаталар алып чыга һәм алты сәгать буена, безнең пехота ярдәмгә килгәнгә кадәр, дошманга каршы көрәш алып бара.

Менә өлкән лейтенант Большаков. Безнең укчы частьләр дошман ныгытмаларының алгы линиясенә килеп җитәләр. Анда бик яхшы яшрелгән, озак вакытка чыдарлык, күп санлы тимер бетон ныгытмалары бар иде. Большаков тикмәгә генә атмый. Күп тапкырлар ул, ак халат киеп, үзе разведкага бара һәм шуннан дошманның кайдан атуын бинокль аша игтибар белән күзәтә. Тирә-якта снарядлар шартлый, пуляләр выжлый. Куркусыз командир бик нык күзәтә. Аннары ул батареягә кайта, утны күзәтелгән урыннарга юнәлдерә һәм дошманның орудиеләрен гаҗәп бер осталык белән бер-бер артлы җимерә.

Танк йөртүче Никита Русин отряд алдына чыгып, траншеяләрдә утырган дошманга каршы ташлана. Пехота атакага хәзер булып, аның артыннан бара. Машинада механик белән янәшә рота командиры утыра. Ул, тимер чыбык белән чолгап алынган дошман траншеяләрен күрә. Пехотага атака өчен яхшы шартлар хәзерләргә кирәк. „Заграждениеләрне өз!" — дип приказ бирә командир.

Танк заграждениеләргә бәреп керә—тимер чыбык шытырдап өзгәләнә, казыклар йомычка кебек вакланалар...

Танк дошманның төп көчләре яшренгән траншеяләргә таба, сулга бара. Танк аларга гранаталар яудыра, аларны кургашын яңгыры астында калдыра, оста маневр ясап, гусеницалары белән рәхимсез рәвештә изә... Озак та үтми, сугыш барган урынга отрядның башка танклары һәм пехота частьләре килеп җитәләр һәм җиңү тәгәлләнә...

Кызыл байраклы Балтык флоты диңгезне дошман операцияләреннән ышанычлы рәвештә саклый.

Безнең су асты көймәләребез дошманның яр буйларында ук куркусыз йөзәләр. Ак финнәр киң җәелгән суга юкка гына миналар куялар! Алар әлегә кадәр тиңдәше булмаган рәхимсез кышка юкка гына өмет бәйлиләр! Көймәләр су астына тирән кереп китәләр, тәүлекләр буе, су төбендә ятып, дошманны көтәләр, һәм хәл иткеч минутта йөзеп чыгалар.

Капитан-лейтенант Трипольский командасындагы көймә, ак финнәргә корал төягән пароход бара дигән хәбәр алды. Көймә аңа каршы ташланды. Озак та үтми, күзәтүче, бортның уң ягыннан дошман карабы бара дигән хәбәрне тапшырды. Тревога сигналы бирелде, барсы да үз урыннарына урнаштылар. Торпеда аппаратлары хәзер тордылар. „Залп!"—һәм куәтле көч белән торпеда диңгезгә атылды, ул туры тиде—дошман карабы тишелде. Көймә су өстенә күтәрелеп чыга һәм дошманга туры текәп ата. Караб ялкынланып яна, аннары тирбәлеп бөтерелә башлый һәм төпкә китә.

Кызыл Армия һәм Кызыл Хәрби Диңгез Флоты геройлары геройлык, куркусызлык, батырлык, җиңүгә булган тыела алмаслык омтылыш үрнәкләрен көн саен күрсәтәләр. Бүләкләнүчеләрнең озын исемлекләренә кергән һәрбер кеше авыр шартларда эшләнгән гүзәл батырлыклар турында сөйли ала.

Карелия бугазындагы, Ладога күле янындагы һәм ак Финляндиянең башка урыннарындагы куәтле ныгытмалар алдында туганнарыбыз ирешә торган бу батырлык эшенә без сокланабыз һәм аның белән горурланабыз.

Бетон оялар шартлый, крепостьларның көле күккә оча, һәм шуның белән бергә империалист әфәнделәрнең кара уйлары да юкка чыгалар.

Дошман никадәр генә көч куймасын, Англия империализмы җитәкчеләре маннергеймнарга булышлык күрсәтүдә никадәр генә юмартлык күрсәтмәсеннәр, Кызыл Армия үз алдына куелган барлык киртәләрне җимерер һәм фин халкына палачларны һәм хиянәтчеләрне илдән куарга ярдәм итәр.

Кызыл Армиянең юлбашчысы иптәш Ворошилов әйткәнчә, совет халкы сугыша белә һәм сугышырга ярата. Безнең илебезнең халкы—геройлар халкы. Ул бары тик бөек, намуслы, яхшы һәм рухландыручы максадлар белән генә коралга тотына.

Кызыл Армия — эшчеләр һәм крестьяннар армиясе—Ватан өчен, коммунизм өчен, Сталин өчен көрәшә.

Империалистик сугышны өештыручылар һәм башлаучылар сугышның чын максадларын яшерергә мәҗбүр булалар. Үз солдатларын сугышка барырга мәҗбүр итү өчен аларны алдыйлар. Алдауга бирешмәүчеләрне алар җәзалаулар белән куркыталар.

Бездә һәр кайда да көрәшне политик яктан аңлату алып барыла. Үз максадларын ачык аңлаучы Кызыл Армия һәм Кызыл Хәрби Диңгез Флоты сугышчылары иң югары данлылык, батырлык, чыдамлылык һәм инициатива дәрәҗәсендә булып чыгалар.

Чыннан да, югарыда күрсәтелгән батырлык эшләренең кайсына гына булса да анализ ясап карыйк. Аларның һәрберсе — безнең сугышчының үзенә хас сыйфатларын ачык күрсәтә. Мисаль өчен тракторчы—сугышчы, бүгенге көндә Советлар Союзы Герое булган Койданы алып карыйк. Койда үзенең төп бурычларын үтәү белән генә чикләнмәгән. Команда пункты сакчылыгындагы кызыл армеецлар ротасының кыенлык кичергәнлеген күргәч, бу тракторчы сугышчыга һәм пулеметчыга әверелә, ә аннары, бөтен патроннарны атып бетергәч, үзенең тракторын сугыш коралы сыйфатында ходка җибәрә, дошманны машинаның корпусы белән таптата, гусеницалар белән басып китә.

23 нче февраль көне—Кызыл Армиябез һәм Хәрби Диңгез Флоты көне, халыкның бөек бәйрәм көне. Бездә халык белән армия бер бөтен, бер семья булып торалар. Халык тарафыннан армиягә бездәге шикелле мәхәббәт һәм игтибар белән карау дөньяда бер җирдә дә юк.

А. Эрлих.

ТАРИХИ БЕЛЕШМӘЛӘР

Г. Поляков коррикатуралары.

Кызыл Армия гражданнар сугышы елларында Антантаның походларын җимереп, патша генералларын тар-мар итте...



Хасан күле районында япон самурайларына җимергеч отпор бирде...

Монголия Халык Республикасы чигендә япон-манжур сугыш чукмарларына онтылмаслык сабак бирде...

Поляк паннарын куып Көнбатыш Белоруссия һәм Көнбатыш Украина хезмәт ияләренә азатлык китерде...

Англия—Франция империализмының бу эте дә шундый ук язмышка дучар булды. Данлыклы Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флоты Финляндия хезмәт ияләрен маннергеймнар - таннерлар коллыгыннан азат итеп җиңүләребез тарихына тагын бер гүзәл сәхифәне язалар.

БОЛГАРИЯ ИЛЧЕСЕ ХРИСТОВ ӘФӘНДЕНЕ ИПТӘШ В. М. МОЛОТОВНЫҢ КАБУЛ ИТҮЕ

Шушы елның 21 нче февралендә СССР Халык Комиссарлары Советы председателе иптәш В. М. Молотов Болгариянен күптән түгел генә билгеләнгән гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре Тодор Христов әфәндене кабул итте.

ШВЕЦИЯ ИЛЧЕСЕ АССАРССОН ӘФӘНДЕНЕ ИПТӘШ В. М. МОЛОТОВНЫҢ КАБУЛ ИТҮЕ

Шушы елның 20 нче февралендә СССР Халык Комиссарлары Советы председателе иптәш В. М. Молотов Швециянең күптән түгел генә билгеләнгән гадәттән тыш илчесе һәм тулы хокуклы министре Пер Вильһельм Густав Ассарссон әфәндене кабул итте.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашучыларны алтын медальләр белән бүләкләү

„Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе турында“ ССР Союзы Халык Комиссарлары Советының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1939 нчы ел, 17 нче февраль карарына туры китереп, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенең Баш Комитеты иң яхшы эш үрнәкләре күрсәткән катнашучыларны—колхоз председательләрен, машина-трактор станцияләре һәм совхозлар директорларын, авыл хуҗалыгы белгечләрен, алдынгыларын һәм оештыручыларын алтын медальләр белән бүләкләде. 1.000 кешегә зур алтын медаль, 2.000 кешегә кечкенә алтын медаль биреләчәк.

Зур алтын медаль белән бүләкләнүчеләр арасында „Заря коммунизма“ колхозының (Горький өлкәсе, Спасское районы) тәҗрибәче колхозчысы, РСФСР Верховный Советы депутаты иптәш С. М. Барышев, атаклы комбайнчы, СССР Верховный Советы депутаты иптәш К. А. Борин, Бурят-Монголия АССР ның Селенгинск районы, Тельман исемендәге колхозның партия оештыручысы иптәш Тогочи Данзанов, „Алга“ колхозы председателе (Горький өлкәсе, Сергач районы) СССР Верховный Советы депутаты иптәш Мостафа Сабиров, Кировтагы өлкә тәҗрибә кырчылык станциясенең директоры академик иптәш Н. Т. Рудницкий, Себердә югары иген уңышы өчен көрәшнең инициаторы, РСФСР Верховный Советы депутаты иптәш М. Е. Ефремов (Алтай крае, Белоглазово районы, „Искра“ колхозы) һәм башкалар бар.

Алтын медальләр белән бүләкләнүчеләргә бер үк вакытта акчалата бүләкләр дә биреләчәк: зур алтын медаль белән бүләкләнүчеләргә 3.000 сум, кечкенә алтын медаль белән бүләкләнүчеләргә—2.000 сум.

(ТАСС)

Чит илләрдә
КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 21 февраль. Кичә фронтта көннең тыныч үткәнлеге хәбәр ителә. Төнлә төрле пунктларда, аерым алганда Вогезы районында һәм Рейндә артиллериянең һәм пехота частьләренең атышулары булган.

БЕРЛИН, 20 февраль. Информация бюросы хәбәр итә: „Бузендорфтан көнбатыштарак Германиянең разведка отряды Франция территориясенә тирән үтеп кергән, якынаеп килүче йөк автомобилен күргән һәм бирелергә тәкдим иткән. Дошман пулеметлардан һәм револьверлардан ут ачкан. Атышу башланган. Германиянең разведка отряды командиры атуны туктатып, бирелү турындагы таләбен кабатлаган. Дошман атуында дәвам иткән. Гранаталар ярдәме белән французларның каршы торуы туктатылган. Француз солдатлары 20 се дә үтерелгән. Немецләрнең ике солдаты җиңелчә яраланган.

БЕРЛИН, 20 февраль. Информация бюросы хәбәр итә: „Германиянең су асты көймәсе Англиянең суднолар караванын озатып баручы „Дэринг“ эсминецын батырган. Сугыш башланганнан бирле Англиянең бары алты гына эсминецын югалтуы турында Англия адмиралтействосының белдерүе дөрес түгел. Кимендә сигез эсминец батырылган. Болардан тыш Англиянең берничә эсминецы нык зарарланган һәм сафтан чыгарылган“.

БЕРЛИН, 21 февраль. Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Германия самолетларының Англиянең һәм Шотландиянең яр буйларына һәм Шетланд атауларына һөҗүм итүләре нәтиҗәсендә Англиянең ике миноносы һәм коралланган сәүдә пароходы батырылган.

ЛОНДОН, 20 февраль. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, үткән атнада (18 нче февральгә кадәр) Англиянең 5 һәм нейтраль илләрнең 15 пароходы батырылган.

Диңгез министрлеге бу югалтуның сугыш башланганнан бирле бер атна эчендә булган иң зур югалту икәнлеген белдерә. Нейтраль илләр һәм Англия белән Франция сугыш башланганнан бирле 1.059.766 тонна авырлыгындагы карабларын югалтканнар. Германия мәгълүматларына караганда, сугыш башланганнан бирле һәлак булган карабларның авырлыгы —1,5 миллион тоннага җитә.

(ТАСС).

МАННЕРГЕЙМГА АКЧА НИЧЕК ҖЫЕЛА

КОПЕНҺАГЕН, 20 февраль. (ТАСС). Копенһагенда агалы-энеле Даельләрнең зур универсаль магазиннарының берсендә хезмәткәрләр арасында ак финнәр файдасына көчләп акча җыела. „Арбейдер-бладет“ газетасының хәбәр итүенә караганда, һәрбер хезмәткәрнең хезмәт хакыннан ай саен 7 кроннан артык акча тотып калалар. Түләргә теләмәүчеләрне хезмәттән чыгаралар. Даельләр үзләре Маннергеймга 100 мең крон акча биргәннәр.

ШВЕЦИЯ „ДОБРОВОЛЕЦЛАРЫ“ НЫҢ АК ФИНЛЯНДИЯДӘН КАЧУЛАРЫ

СТОКҺОЛЬМ, 21 февраль. (ТАСС). Швециядә чыга торган „Норрботтенс куририен“ газетасы күптән түгел генә ак Финляндиядәге швед „доброволец“лары арасында чистарту үткәрелгәнлекне хәбәр итә. Газета болай дип яза: „Доброволецларның сугыш сәләте бик түбән. Аларны өйрәткән саен аларның рухы һәм настроениеләре кими бара“

Көчләп тупланган швед „доброволец“лары Маннергейм режимының авырлыкларын җилкәләрендә татып ак Финляндиядәге „доброволец“ лар частьләреннән качалар. Газета „Доброволецларның кечкенә группалар булып чик аркылы өйләренә кайтуларын көн саен диярлек күрергә мөмкин“, дип икрар итәргә мәҗбүр.

ЛИТВАДА ЭЛЕККЕ ПОЛЯК ОФИЦЕРЛАРЫНЫҢ КАЗЫНУ ЭШЕ

КАУНАС, 21 февраль. (ТАСС). Вильнода демонстрация оештырырга һәм илдә тәртипсезлекләр китереп чыгарырга маташкан элекке поляк офицерларын яңадан кулга алулар булган. Литва дәүләтенә каршы юнәлдерелгән күп кенә листовкаларга конфискация ясалган.

Үзләренең җимерү эшләрен поляклар „дини“ һәм „культура“ эше белән яшерергә маташалар. Үзләренең провокацион эшләрендә алар хәтта балалардан да файдаланалар.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

18 һәм 19 нчы февральдә Гуандун провинциясендә Сватоудан төньяктарак японнар 2 мең кешелек десант төшергәннәр. Кытайлар нык̧лы каршылык күрсәткәннәр. Шунлыктан десант Кытай территориясенә тирән үтеп керә алмаган. Кытай чыганакларыннан алынган мәгълүматларга караганда, курчак хөкүмәт гаскәрләреннән 1.800 солдат 19 нчы февральдә японнарга каршы восстание күтәргән һәм үзләре белән 1.500 винтовка, 20 пулемет һәм башка сугыш кирәк-яраклары алып кытайлар ягына чыккан.

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә Наньнин секторында сугышлар дәвам итә.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Кытай гаскәрләре японнарны Сисиннән (Сяошаньнән көнбатыштарак) бәреп чыгарганнар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Японнар тылында хәрәкәт итүче кытай частьләре соңгы көннәрдә Гуйхуадан 100 километр чамасы төньяк-көнчыгыштарак Баотоу—Даолинь районында күп кенә атакалар ясаганнар.

Кытай гаскәрләре Шаньси провинциясенең көньяк - көнчыгыш өлешендә Луаньфу секторында японнарның юлларын кисеп күп кенә пунктларны алганнар.

КЫЗЫЛ АРМИЯ ҖЫРЛАРЫ һӘМ БИЮЛӘРЕ АНСАМБЛЕ

Кызыл Армия үзенең чиксез батырлыгы, Ватанга чын күңелдән бирелгән, җиңелмәс сугышчы булуы белән генә түгел, бәлки көчле талантлар, иҗад көчләре тәрбияләп үстерә торган мәктәп булуы белән дә данлыклы. СССР халык артисты А. В. Александров җитәкчелегендә Кызыл Армия җырлары һәм биюләренең Кызыл Байраклы Бөтенсоюз Ансамбле героик Кызыл Армиябезнең мактанычы булып тора. Ул ансамбль безнең Советлар Союзында гына түгел, бәлки бөтен дөнья күләмендә дә дан тота. Илебезне дошманнардан саклау юлында геройларча көрәшүче шанлы Кызыл Армияне ул яңадан-яңа җиңүләргә дәртләндерә. Аның искиткеч җанлы, матур җыр һәм биюләрен тыңлап һәм карап кем генә, кайсы гына сугышчы рухланмый?!

Волга буе Хәрби Округының Кызыл Армия җырлары һәм биюләре ансамбле әнә шул кызыл байраклы, үзәк ансамбльнең баласы. Волга буе хәрби частьләрендәге кызыл армеецлардан һәм кече командирлардан торган бу ансамбль 1939 нчы елның 19 нчы мартында, Советлар Союзы маршалы иптәш Ворошилов приказы буенча оештырылган иде. Кызыл Армия частьләренә художество хезмәте күрсәтү һәм Кызыл Армия иҗадын киң катлау кызыл армеецлар арасына тарату бу ансамбльнең төп бурычы булып тора. Ансамбль Кызыл Армия частьләрендә зур авторитет белән файдалана. Кызыл Армия частьләре шушы ансамбльдән үрнәк алып, шул тип буенча, кызыл армеецларнең үзешчәнлек коллективларын оештыралар. Оештырылувына әле бер ел да тулмаган бу яшь ансамбль инде зур гына эшләр эшләде һәм зур уңышларга ирешде. Волга буе өлкәләрендә һәм автономияле республикаларындагы частьләрдә бу ансамбльне һәр кем диерлек белә.

Шушы кыска вакыт эчендә ансамбль 150 дән артык зур концерт бирде. „80 ләп концерт биргән айлар булды“—ди ансамбльнең җитәкчесе иптәш Кукаретин. Ансамбльгә төрле шартларда эшләргә туры килә. Ул кырда, хәрби өйрәнүләр вактында, автомашина өстендә, ачык эстрада сәхнәләрендә дә чыгышлар ясый. Барлык шартларда да коллектив зур энтузиазм белән эшли.

Бу ансамбль Казанда ике тапкыр булды. Беренче тапкыр аны үткән җәй лагерда тыңлаган идек. Шушы арада ул Казанга икенче тапкыр килеп, Кызыл Армия йортында һәм хәрби частьләрдә берничә концерт бирде. Ансамбль хәзер тагы да үскән, аның программасы яңарган, тулылангән.

Александровның „Сталин турында җыр“ы, „Большевиклар партиясе гимн“ы һәм „Ворошилов турында җыр“ ансамбль башкаруында гаять көчле һәм күтәренке яңгырыйлар. Гейфманның Көнбатыш Белоруссияне азат итүгә багышланган „Шел боевой отряд“ дигән әсәрен ансамбль бик матур һәм дәртле итеп башкара. Аталы-уллы Демидовлар төрле гармоннарда Дунаевскийның „Физкультура маршы“н, Книпперның „Степная кавалерийская“сын зур осталык белән уйныйлар. Кечкенә гармонда башкарылган рус халык көе һәм Саратов частушкалары тамашачыларда яхшы тәэсир калдыра. Новиковның „Хасан төне“н халык яратып тыңлый.

Бөтен ансамбль тарафыннан матур һәм моңлы итеп башкарыла торган „Запевайте хлопцы песни“ җыры һәм зур бию белән беренче бүлек тәмам була. Ансамбльнең биюләре искиткеч матур, җанлы һәм рухлы. Ансамбль биегәндә тамашачы тыныч кына утыра алмый. Бөтен зал тәэсирләнә, шаулый. Никадәр яшьлек, матурлык һәм дәрт бар бу биюләрдә! Аларда тормыш аңкый. Биюләр җитәкчесе кызыл армеец Гордейчук зур осталык күрсәтә.

Сталин турында казак җыры да, шулай ук халык җыры „Калинка“ да аеруча көчле һәм рухлы яңгырыйлар.

Иң ахырда, Ерак Көнчыгыш частушкаларын һәм Кызыл Армия биюләрен ансамбль искиткеч осталык һәм зур темперамент белән башкарып, тамашачыларда гаять көчле тәэсир калдыра. Зал көчле алкышлар белән күмелә.

Кызыл Армиянең XXII еллыгына ансамбль Кызыл Армиянең сугышчан юлын гәүдәләндерә торган әйберләрне, Украина халык җыры „Заковала та Сива Зазуля“ны, Волга турында җырлар циклын һәм башкаларны хәзерләде. Май бәйрәменә юлбашчылар турында җырлар хәзерләнәчәк.

Ансамбль башкаруында татар җырлары һәм биюләрен дә ишетәсе, күрәсе килә.

М. Яхин.

БӘЙРӘМ ХӨРМӘТЕНӘ

ТЕАТРЛАРДА

Казанның Зур Драма театры бүген, 23 нче февральдә көндез һәм 25 нче февральдә кич кызыл армеецлар, начальниклар составы һәм аларның семья членнары өчен махсус спектакльләр куя. Тамашага бүген „Ленин“ пьесасы, 25 нче февральдә „Бакчалар чәчәк ата“ пьесасы куела.

Театр коллективы тарафыннан билгеләнгән художество бригадалары Кызыл Армия частьләренә культура хезмәте күрсәтәләр.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театрында бүген көндез, театр шефлыгындагы частьләрнең активы белән берлектә театр работникларының XXII еллыкка багышланган тантаналы җыелышы була. Частьләрдән килгән кунаклар өчен җыелыштан соң „Бишбүләк“ пьесасы куела. Шулай ук кичке спектакльгә дә кызыл армеецлар, командирлар һәм политработниклар чакырылды.

КЛУБЛАРДА

Серго Орджоникидзе исемендәге клубта кызыл армеецлар, командирлар һәм допризывниклар өчен художество кичәләре оештырылды.

Бәйрәм уңае белән бүген завод коллективы өчен зур концерт бирелә. Концертка кызыл армеецлардан һәм командирлардан да кунаклар чакырылды.

XXII еллык уңае белән сәүдә работниклары клубында бүген художество кичәсе үткәрелә: Кичәдә данлыклы ел турында доклад тыңланачак һәм Хасан күле районындагы сугышта катнашкан иптәшләр белән очрашу булачак. Клубның үзешчәнлек сәнгате түгәрәкләре тарафыннан Кызыл Армия тормышыннан әдәби-музыкаль монтаж куела.

Бүген пионерлар һәм мәктәп балалары йортында Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының XXII еллыгы уңае белән костер була. Данлыклы ел турында беседа үткәрелә һәм „Федька“ кино-картинасы күрсәтелә.

Менжинский исемендәге клубта бүген XXII еллыкка багышланган зур кичә була. Кичәдә гражданнар сугышында катнашкан карт большевик иптәш Лобанов Кызыл Армия һәм Хәрби Диңгез Флоты турында доклад ясаячак. Соңыннан Дәүләт Филармониясенең Горький шәһәреннән килгән сәнгать бригадасы һәм Казан Дәүләт университеты студентларыннан торган үзешчәнлек сәнгате көчләре тарафыннан концерт биреләчәк.

24 нче февральдә бәйрәм хөрмәтенә балалар иртәлеге үткәрелә.

МУЗЕЙДӘ КЫЗЫЛ АРМЕЕЦ КӨНЕ

Татарстанның Крайны Өйрәнү Үзәк Музее 23 һәм 24 нче февральдә „Кызыл армеец көне“ үткәрә. Бу көннәрдә кызыл армеецлар музейга түләүсез кертеләләр. Килүчеләргә музейнең барлык работниклары хезмәт күрсәтәчәкләр.

XXII ЕЛЛЫККА БАГЫШЛАНГАН КРОСС

Казан Дәүләт университетының физкультурниклары данлыклы еллыкка багышлап чаңгыларда кросс үткәрәләр. Кросска старт бүген көндез 2 сәгатьтә университет янында биреләчәк.

ФОТО-КҮРГӘЗМӘ

Казан Партия Мәгарифе йортының китапханәсе данлыклы XXII еллык уңае белән фото-күргәзмә оештырды. Күргәзмәгә фотодокументлар белән бер рәттән, Кызыл Армия турында чыккан әдәбият та куелды.

СӘНГАТЬ БРИГАДАЛАРЫ

Татарстан Дәүләт Филармониясе юбилей көннәрендә хезмәт күрсәтү өчен сәнгать бригадалары оештырды. Бәйрәм көннәрендә алар оборона тематикасындагы программалар белән чыгалар.

Татарстанның атказанган артисткасы иптәш Әхметова җитәкчелегендәге татар биюләре һәм җырлары ансамбле гражданнар сугышы җырларыннан „Кызыл Армия маршы“ н, „Гөлсара“ җырын, орденлы композитор Александров тарафыннан эшләнгән „Тыңла, сугыш башланды“ дигән җырны башкара. Шулай ук программада композитор Новиковның Хасан күле турындагы җыры, Мәҗитевнең „Батыршин маршы“, Җәүдәт Фәйзинең „Кавалерия җыры“, композитор Ключаревның „Көчләләр“ җыры, Дунаевскийның „Ватан турында җыр“ы, Ковальның „Кызыл Армия алга“ дигән биюләре башкарыла.

Бригадалар бүген 12 концерт бирәчәкләр. 1 нче мартка кадәр хәрби частьләрдә 5 концерт бирелә.

РЕДАКЦИЯДӘН

Газетабызның 20 нче февраль номерындагы баш мәкаләдә Киров районындагы „Красное Знамя“ артеле партбюросы секретаре иптәш Халитов, коммунистларның ышанычын акламавы өчен, бу сайлауларда яңа составка кертелмәде, дип ялгыш киткән. Яшрен тавыш бирү тәртибендә иптәш Халитов партбюро секретаре итеп яңадан сайланган һәм аның эше канәгатьләнерлек табылган.

Шуның белән редакция үзенең ялгышын төзәтә.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

ТАТНАРКОМСОБЕС

агротехниклар хәзерләү мәктәбенә,

III нче группа инвалидлардан шушы ел 1 нче мартка кадәр

УКУЧЫЛАР АЛА

Уку срогы 1 ел. Укучыларга стипендия, туклану һәм тулай торакта урын бирелә. Мәктәпкә керүчеләрдән кимендә 5 класс күләмендә белем сорала.

Документлар белән гариза җибәрү өчен адрес: Казан, Тукай урамы, 5, Татнаркомсобес. 351—3—1

Хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитетының карары нигезендә, шушы ел 24 нче февральдән,

9 һәм 10 нчы маршрут трамвайларында йөрү өчен

түләү бәяләре буенча

БЕРДӘМ ТАРИФ КЕРТЕЛӘ:

1. Шәһәрдән Серго Орджоникидзе исемендәге заводның иске управлениесенә кадәр (диспетчер пункты) 15 тиен.

2. Иске управлениедән Серго Орджоникидзе исемендәге заводка кадәр (9 нчы маршрутның ахыры) 15 тиен.

3. Серго Орджоникидзе исемендәге заводның иске управлениесеннән (диспетчер пунктыннан) шул ук Заводның ИТР лар поселкасына кадәр (10 нчы маршрутта) 15 тиен.

4. Шәһәрдән Серго Орджоникидзе исемендәге заводка кадәр 30 тиен.

353—2—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

23 һәм 24 нче февральдә ПРЕМЬЕРА

ЛЕНИН

23 нче февральдә талон 107.

24 нче февральдә көндез

МАСКАРАД

Талоннар: көндез 22, кич 108.

Заявкалар алына.

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

Бүген, 23 нче февральдә

БИШБҮЛӘК

Талон 122.

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык.

ТДАТ.

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ

Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры бинасында

24 һәм 27 нче февральдә ПРИМЬЕРА

ИРЕК

24 ндә талоннар белән кертелми.

27 ндә талон 78.

Билетлар ТДАТ кассасында алдан сатыла. Операга коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

2—1

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген һәм һәр көн Москваның Ленин орденлы Дәүләт циркы артистларының гастроле

СТРАТОС—3

Номерлар орденлы артист БАСТ җитәкчелегендә башкарыла. Аэропланда үлем элмәкләре һәм башка күп номерлар.

РСФСР ның атказанган һәм орденлы артисты **М. ЗОЛЛО** гастрольләре дәвам итә.

Уен кич 8 дә башлана.

Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ЧАПАЕВ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8 һәм 10 да	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„Колхозник“ 4, 6, 8 һәм 10 да.	КЫЗЫЛ АРМИЯ
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ИУДА
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8, 10 да.	ПАТРИОТ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	БАЛТЫКЧЫЛАР
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	СОҢГЫ ТӨН

КИРӘК:

Даими эшкә КОЧЕГАРЛАР. Тору урыны бирелә. Казан, Киров районы, Гладилов урамы, 59, Җитен комбинатының кадрлар бүлеге. 347—1

Татарстан АССР районнарында мәктәп төзелеше буенча прораб булып эшләү өчен ТӨЗҮЧЕ ТЕХНИКЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча. Квартира бирелә. Казан, Кремль, Татнаркомпрос. Телефон № 26—62. 348—2—1

Даими эшкә, төзелеш эшләре буенча БАШ БУХГАЛТЕР (оклад 800—1000 сум), бүлек өчен ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР (оклад 600—650 сум) һәм ХИСАПЧЫЛАР (оклад 300—350 сум). Казан, Кызыл Армия бистәсе, Октябрьнең 10 еллыгы исемендәге урам, 8, заводның кадрлар бүлеге. 352—1

„Урак һәм чүкеч“ заводына даими эшкә КОНСТРУКТОРЛАР, КОНСТРУКТОРЛАР БЮРОСЫ МӨДИРЕ, КОНТРОЛЬ МАСТЕРЛАР, ТЕХНОЛОГЛАР, ВАХТЕРЛАР (охранниклар), СЛЕСАРЬ-ЛЕКАЛЬЩИКЛАР, 4, 5 һәм 6 нчы разряд МОДЕЛЬЧЫЛАР, 3, 4 һәм 5 нче разряд ТОКАРЬЛАР 3, 4 һәм 5 нче разряд ШЛИФОВАЛЬЩИКЛАР. Кызыл Армия бистәсе, Клара Цеткин урамы, 10/12, заводның кадрлар бүлеге. 315—2—1

Камил Якуб исемендәге китап фабрикасына ПЛАННАР БҮЛЕГЕ НАЧАЛЬНИГЫ, ЭКОНОМИСТ - ПЛАНОВИК һәм СЧЕТ РАБОТНИКЛАРЫ Казан, Бауман урамы, 19, Матбугат йорты ишек алдында. Кадрлар бүлегенә килергә. 209—2—2

Уполн. Главлита ТАССР. № А — 728 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 743.